## Ислам кагыйдәләре

# Еш укылган Коръән сүрәләре

### «Фатихә» сүрәсен уку сәбәпләре

**(Дәвамы. Башы 2012 елның 6нчы санында)**

Бу мөбарәк сүрәнең мөселман халыклары арасында шулкадәр еш укылуының бик күп сәбәпләре бар.

Беренчедән, Аллаһы Тәгалә бу сүрәне Коръәннең калган өлешеннән аерып, «кабатланган җиде (җөмлә)», дип хөрмәтләп атаган.

Икенчедән, сөекле Пәйгамберебез бу сүрәне олылап, «Коръәннең иң бөек сүрәсе», дип атаган һәм аны һәр намазның һәр рәкәгатендә укыган.

Өченчедән, Пәйгамбәребез хәзрәти Мөхәммәд (галәйһис-сәлам) бу сүрәне олылап, аңа хөрмәтен чагылдырган төрле исемнәр биргән. «Фатихә» сүрәсен аерым хөрмәт итеп, аны һәртөрле очракларда, чараларда укуның башка сәбәпләре исә аның исемнәрендә чагылган.

### «Фатихә» сүрәсенең исемнәре

Галимнәр бу сүрәнең 30га якын исеме барлыгын сөйлиләр. Алар барысы да аның хикмәтләрен һәм тирән мәгънәләрен чагылдыра.

Югарыда аның шушы исемнәре турында язылган иде. Мәшһүр исемнәре исә шулар:

1) «Фатихә» - ачучы, ягъни Коръәнне башлап җибәрүче дигән мәгънәне аңлата.

2) Эчендәге күптөрле шифалардан чыгып, «Шафия», ягъни «шифалаучы, шифа бирүче» һәм «әш-шифа», «сүратуш-шифа», ягъни «шифа» сүрәсе исеме.

3) Эчендәге мәгънәви көченең кешене зарарзыяннан, сихер-бозымнан саклавына нигезләнеп, бу сүрәгә «әр-рукья», ягъни «саклаучы», «бөтү» исеме бирелгән.

4) Эчендә дога аятьләре булганга, «әд-дуга» «сүратуд-дуга», ягъни «дога», «дога сүрәсе», дип аталган.

5) Дога кылу, ялвару, сорау, теләү, таләп итү мәгънәләрен үз эченә алганга, бу сүрәгә «сүратут-таләб» (теләү, таләп итү сүрәсе) һәм «сүратус-суаль» - сөаль, сорау, үтенү сүрәсе диелгән.

6) Бер өзлексез бөтен намазларның һәр рәкәгатьләрендә мәҗбүри укылганга (димәк кабатланылганга), «сәбгуль-мәсани», ягъни «кабатланган 7» аять диелгән.

7) Намазларда укылуы мәҗбүри, ансыз намаз саналмаганга, ягъни намазның бер рөкене, мөһим өлешен тәшкил иткәнгә, аңа «сүратус-саләһ», ягъни «намаз сүрәсе» диелгән.

8) Изге Китабыз Коръәни-Кәримнең эчтәлеген үз эченә алганга күрә, «үммүл-Куръән», ягъни «Коръәннең анасы» диелгән.

9) Әл-вафия — күп нәрсәне үз эченә алган эчтәлекле, мәгънә һәм хикмәткә бай дигәнне аңлаткан исем бирелгән.

10) Әл-Кафия — җитәрлек булган. Ягъни гади укудан башлап, намазда укуга хәтле булган — һәр халәттә берүзе генә укылган очракларда да җитәрлек дигәнне аңлата. Дога кылганда «Фатихә»не генә уку да дога буларак санала.

11) Әл-хәмд (сүратул—хәмд, ягъни «мактау» сүрәсе). Сүрә Аллаһыны мактау («Әлхәмдүлиллаһ» әйтү) белән башланганга, эчтәлеге Аллаһыны мактау булганга, шушы исем бирелгән.

Шушы «әл-хәмдү» сүзе белән мәгънәдәш «шөкер», ягъни рәхмәт әйтеп мактау сүзеннән бу сүрәнең тагын бер исеме «сүрәтүш-шукр» - «шөкер итү, шөкрана кылу, ягъни рәхмәт әйтү» сүрәсе барлыкка килгән.

12) «Ән-Нур», «сүратун-нур», ягъни «нур сүрәсе». «Фатихә» сүрәсе үзе мөселманнар өчен бер нур, яктылык булганга, һәм эчендә нурга, һидаятькә, тугрылык, дөреслеккә ия булу теләге - бозыклыкка, караңгылыкка, адашуга (далаләт) төшкәннәр («әддаллин») эчендә, арасында булмау, андыйлар аерылу теләге булганга, бу сүрәгә шушы нур сүрәсе исеме бирелгән.

13) Коръәннең асылы, үзәге дигән исеме.

14) Әл-Кәнз — хәзинә дигән исеме.

### Йомгак

«Фатихә» сүрәсе гарәп-мөселман дөньясында без төрки-татар халыкларында гел хөрмәт ителеп, бертуктаусыз укылып, йөз еллар буе телләрдән төшерелмичә килгән һәм иншаАллаһ киләчәк тә.

Дөрес, халкыбыз балаларга иң элек «Ихлас» сүрәсен (Куль һуаллаһу әхәдне) өйрәтүне гадәткә керткән. Бу — «Ихлас» сүрәсенең төп мәгънәсе, асылы Аллаһыны берләү, ширекне кире кагу, инкарь итү булганга күрә. «Ихлас» сүрәсенең кыскарак булуы, балага истә калдыру өчен уңайлырак булуы да роль уйнагандыр. Әмма бала чагында «Фатихә»не өйрәнмәгән, өйрәтеп тә өйрәнә алмаган кешеләрнең дә «Фатихә» сүрәсен ишетмәгәне булмагандыр. Чөнки азмы-күпме, кечеме-олымы, һәрбер вакыйгада бабаларыбыз Коръән укыганнар һәм Коръән укуның башында «Фатихә» сүрәсен укыганнар.

Әгәр гарәп, башка мөселман халыклары Пәйгамбәребезнең сәхабәсе Габдуллаһ ибне Габбас әйткән «авыру булганда яки берәр җиреңә зарланган вакытта Коръәннең нигезенә, (ягъни «Фатихә» сүрәсенә) ябыш (ягъни аны укудан аерылма, дәвамлы, бертуктаусыз укы)», дигән сүзләренә ияреп, бу сүрәне шул очракларда гына укырга гадәт итсәләр, безнең төрки-татар халкы аңа гомер барышында һәр җитди очракларда ябышырга, аннан аерылмаска тырышкан.

Халкыбызның Коръән укуны — «бер Әлхәм, өч Кольһуваллаһ уку», дип гадәт иткәне, Коръән укуны шулай дип белгәне дә шул аерым махсус хөрмәттән, мөбарәк вә газиз Коръәннең бу өлешеннән аерылмаска тырышуыннан киләдер.

Бу хөрмәт һәм аерылмауның сәбәбе «Фатихә» сүрәсенең үзендә, аның хисапсыз хикмәтләрендә, тирән мәгънәләрендә һәм бай эчтәлегендә. Чөнки ул - бөтен нәрсәне эченә алган бер нәрсә. Пәйгамбәребез бу сүрәне җирдә яшерен булган, читтән күренмәгән, әмма үзенә тап булган кешене исәпсез байлыкка ия иткәнгә күрә, «Фатихә» сүрәсе - бер бетмәс хәзинә, «ул - Коръәннең бер өлеше дә, ул авыруларга шифа да, ул үтенү-сорау да», дип әйткән.

**Иршат хәзрәт САФИН.**

## Сорау-җавап

### Тәһарәтле уку тиешле

**Намаз кылмаган кешенең Коръән укуы дөресме?**

Коръәнне укыр өчен, әлбәттә, кеше пакь булырга тиеш. Тәһарәтсез һәм госелсез аны кулга алу һич тә дөрес түгел. Күңелдән тәһарәтсез укырга ярый, ә госелсез күңелдән дә укый алмый. Намаз укымаган кешенең Коръән укырга теләге бар икән, тәһарәтле булса, укырга мөмкин.

### Тәҗвидле уку тиешле

**Коръәнне урыс алфавиты белән өйрәнеп укырга ярыймы, тәҗвидсез ярыймы?**

Тәҗвид белән уку вәҗиб, диелгән хәдис бар. Әгәр Коръәнне тәҗвид белән өйрәнеп укысаң, нинди хәреф белән булса да ярый. Дөрес укымасаң, гарәп хәрефе белән булса да хата - хата инде ул. Әгәр шуның мәгънәсе дә бозылырлык игътибарсыз укысаң, яки дәрәҗә өчен, яки мал җыяр өчен укысаң, гөнаһлы булганы һәркемгә билгеле инде. Син укыма алай, ярамый, дип туктатмыйча, менә болайрак, дип төзәтсәң, һәр ике як саваплы була.

### Тәфсир - дога түгел, аңлатма гына

**Миндә «Коръән тәфсире» бар. Хәзрәт: «Бу китапны ераграк тотыгыз, ул Ногмани хәзрәтләренең чын тәфсире түгел», - диде. Аның белән файдаланырга буламы? Укып, әрвахлар рухына багышларга ярыймы?**

Һәр кеше әйтергә теләгән фикерен үз калебе аша үткәреп, үзе аңлаганча яза. Коръән тәфсире белән дә эш шулайрак тора. Нурулла хәзрәт чыгарган «Коръән тәфсире», нигездә, Ногмани тәфсиреннән алынган. Ләкин Нурулла хәзрәт җәяләр эчендә бик үк дөрес булмаган үз аңлатмаларын биргән. Мәсәлән, алар: «Коръән фәкать тере кешеләр өчен иңдерелгән, үлеләр өчен түгел», «Дога юк, бернәрсә юк», дип хаталаналар. Ә Коръән сүрәләрендә, аятьләрендә: «Ата-аналарга дога кылыгыз, башка мөэминнәргә дога кылыгыз», дигән сүзләр тулып ята («Мөэмин», «Хиҗер» һ.б. сүрәләр). Аллаһы Тәгалә - җанны да, тәнне дә яралтучы. Шуңа күрә Аллаһыбыз Коръәнендә иңдерелгән аятьләр иман әһеленең җанына да, тәненә дә файда бирәләр. Тәфсир укуны, хаслап, Коръән уку дип аңламаска кирәк. Аны укып, әрвахлар рухына багышлау ярамас. Чөнки Коръән тәфсирен, Аллаһы Тәгалә Коръәндә нәрсә әйткән икән, дип укыйбыз. Ләкин шунысы да бар бит әле: салават әйтәбез дә, теләк теләп, Аллаһы Тәгаләдән кирәген сорап, дога кылабыз. Биредә дә дога кылырга ярамый, дип әйтергә хакым юктыр, һәрхәлдә. Коръән тәфсирендә аятьнең үзе түгел, бары тик аңлатмасы гына язылган. Ә аятьнең үзен әйтмичә, тәрҗемәсен генә әйтү дөрес түгел.

### Тәфсирне укып иманыңны ныгытасың

**Коръән тәфсирен дога итеп укырга ярамый, дип ишеттек. Ягъни мәеткә яки үзең өчен тәфсирне укырга ярамый, дип.** Коръән тәфсирен укып, үзеңнең иманыңны ныгытасың һәм үзеңә тиешле бурычларыңны һәм нәрсәләрдән тыелырга кирәген беләсең. Шулай итеп, әҗер-саваплар эшлисең. Догаларны Коръәни-Кәримнән уку хәерле.

### Коръәнне гарәпчә, доганы ана телендә уку дөрес

**Мин гарәп телен белмим. Шулай булгач, ни догаларны, ни намазны укырга өйрәнеп булмый. Бу бичара татар халкының үз телендә дине дә юк бит, бер милләт кешесе дә ят телдә дин тотмый, югыйсә. Намазны татарча гына укырлык итеп, андагы догаларны татарчага тәрҗемә итеп бастырсагыз, күп кешеләр үз телләрендә намаз укыр иде.**

Аллаһы Тәгалә каршында дин - фәкать Ислам дине генә, башка дин юк. Һәр милләт кешесе үз телендә гыйбадәт кыла, дип ялгыш уйлый бу зат. Һәр милләт кешесе үз телендә дога гына кыла ала, ягъни Аллаһыны ярдәмгә чакыра, үз хаҗәтләрен үтәүне Аңардан сорый. Ә диннең гыйбадәте бары тик Аллаһы Тәгалә теләгәнчә, Ул кушканча гына булырга тиеш.

Соңгы Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-сәлам гарәп булып килде, аңа иңдерелгән Коръән-Кәрим дә гарәп телендә иде. Шушы Пәйгамбәр һәм шушы Коръән-Кәрим - икесе дә кыяміткәчә барлык халыклар (ни гарәп, ни татар, ни башка милләтләр өчен генә түгел) җибәрелде. «Без сине җибәрмәдек башка затлар шикелле. Фәкать адәмнәргә, барлык адәмнәргә Пәйгамбәр итеп җибәрдек. Кем Ислам диненнән башка динне тота икән, һичбер вакыт кабул ителмәячәк», диде Аллаһы Тәгалә. Бу - Аллаһыбызның Коръән-Кәримдә язылган сүзләре.

**«Гыймран» сүрәсендәге сүзләр**

Соңгы аятьләрен иңдергәндә: «Сезгә динне камил хәлгә китердем, нигъмәтемне тәмамладым. Шуны тотып баруыгыздан Мин разый булам. Бу дин - Ислам динедер», - дип Аллаһы Тәгалә ахыргы сүзләрен тәмамлый. («Гыймран» сүрәсе, 3 нче аять). Шуңа күрә Ислам диненнән башка динне тотучыларның теләкләре кабул була алмый. Ә гыйбадәт Аллаһы Тәгалә күрсәткән гарәп телендә генә булырга тиеш. «Фатихә» сүрәсе икән - үзенчә укы, «Ихлас» сүрәсе икән - үзенчә укы, башка сүрәләрне дә Коръән-Кәримдәгечә укырга кирәк. Башка милләт кешеләренең дә гыйбадәтләре Аллаһы кушканча, Пәйгамбәребез кушканча, намаз уку иде. Алар Ислам диненнән тайпылдылар. Безнең татарларның да күбесе намазны ташлады, шуның белән гыйбадәтнең чын асылын да аңламас булды. Алар башка диндәге кешенең кыла торган догаларын гыйбадәт кылу, дип уйлыйлар. Дога гыйбадәт түгел ул, дип әйтмим мин. Ләкин Аллаһыга коллык күрсәтә торган гыйбадәт намазын - үз хәлендә, ә дога гыйбадәтен, рәхим итеп, ана телендә укыгыз.

***Габделхак хәзрәт САМАТОВ.***
***(«Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабыннан)***